УДК 398(=512.145)

# Татар фольклорында изгеләр образы

*С. Г. Сәмитова,*

*Республика традицион мәдәнияте үстерү үзәге,*
*Казан шәһ., Татарстан Республикасы,*
*Россия Федерациясе*

# Images of Saints in Tatar folklore

*S. G. Samitova,*

*The Republican Centre for Development of Traditional Culture,*
*Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**
В статье рассматриваются татарские легенды и предания о святых и сакральных местах Закамья, связанных с именами святых. Предпринимается попытка научного осмысления семантики и этимологии легенд и преданий через призму религиозных верований, в частности – суфизма. Подвергаются исследованию сюжеты и образы, их притязания на достоверность. В основу статьи легли материалы фольклорно-этнографической экспедиции в Аксубаевский район Республики Татарстан (16-19 августа 2019 г.).

**Abstract**
The article deals with Tatar legends and tales about Saints and sacred places associated with the names of Saints. The work presents an attempt of scientific understanding of semantics and etymology of legends and tales from the perspective of spiritual beliefs, particularly Sufism. Plots and characters, as well as their authenticity claim, are analyzed. The article is based on the materials of a folklore-ethnographic expedition to Aksubayevsky district of the Republic of Tatarstan (August 16-19, 2019).

**Ключевые слова**
Легенды, предания, татарский фольклор, сакральные места, национальные традиции, религия, мистика, образы святых, семантика.

**Keywords**
Legends, tales, Tatar folklore, sacred places, national traditions, religion, mysticism, images of Saints, semantics.

Татар фольклоры төрле яклап өйрәнелгән булса да, озак вакытлар галимнәр игътибарыннан читтә калып килгән темалар бар. Шуларның берсе дин белән бәйле. Әлеге тема өстендә инде рус галимнәре гасырдан артык вакыт эзләнәләр. Рус һәм Европа фольклористикасында сакраль урыннарны өйрәнгән, «изгеләр» культы белән бәйле риваять-легендаларның этимологиясен ачуга багышланган фәнни чыганаклар байтак. Мәсәлән, А. Дж. Арберри,

В. Н. Басилов, В. В. Бартольд, А. Гольциер, Р. Р. Исхаков, И. Р. Насыров, А. Г. Селезнев һәм И. А. Селезнева кебек галимнәрнең хезмәтләрен атарга була[1]. Бу хезмәтләрдә дини мистик сюжетларга корылган халык әсәрләре, аларда тасвирлаган вакыйгалар һәм изгеләштерелгән персонажлар, алар исеме белән бәйле изге урыннар өйрәнелә.

Татар халык иҗатында һәм этнографиясендә бу тема соңгы берничә дистә ел эчендә генә өйрәнелә башлауга карамастан, җитди хезмәтләр дөнья күрде. Фольклорчы галимә А. Х. Садыйкова татар фольклорына ислам идеологиясенең йогынтысын, аерым образларны һәм мотивларны өйрәнде[2]. Галимә Хозыр Ильяс һәм төркиләрдә изгеләштерелгән Искәндәр Зөлкарнәй образларына киң туктала. Фольклордагы аерым дини, мифологик образлар турында Ф. И. Урманчеевның өч томлык «Татар мифологиясе» энциклопедик сүзлегендә мәгълүмат табарга мөмкин[3]. Татар шигъриятендә дини мистик һәм мифологик күзаллаулар, төш алымы, аларны юрау үзенчәлекләренә Ф. З. Яхин тирән анализ бирә, татар әдәбиятында суфичылык йогынтысын Ә. Т. Сибгатуллина өйрәнә[4]. Болгар һәм Алтын Урда чорлары татар авыз иҗатына бәйле рәвештә И. Г. Закирова хезмәтләрендә ачыла[5]. Бу мәкаләдә тикшерелгән изге образлар сакраль урыннарга бәйле рәвештә Ф. Х. Җәүһәрова, Р. К. Уразманова, Г. Ф. Габдрахманова, А. Р. Мухаметзянова хезмәтләрендә ачыклана[6]. Бу хезмәтләрдә Татарстан җирлегенә булган сакраль урыннар барлана, бу урыннар белән бәйле ритуал-йолаларның структурасы өйрәнелә.

Безнең максатыбыз – татар фольклорында таралган изгеләр образын барлау, алар белән бәйле риваять-легендаларны ачыклау, тематикасын классификацияләү, изге персонажлар һәм урыннарга мөнәсәбәтле туган халык ышануларын өйрәнү, аларның этимологиясен ачыклау.

Изгеләр образының формалашуы мәҗүсилек чорыннан башлана. Ислам дине изгеләрне канонлаштыруга каршы, чөнки Аллаһ бердәнбер табынуга лаеклы зат. Әгәр дә без кемне дә яки нәрсәне дә булса культ дәрәҗәсенә күтәрәбез икән, бу исламда Аллаһ тарафыннан кичерелмәс гөнаһ санала. Шулай да, халык фантазиясе, аерым шәхесләрне гайре табигый көчкә ия итеп сурәтли. Аларны гадәттә «изгеләр» атамасы белән йөртәләр. Галимнәр фикеренчә, бу күренеш тамырлары белән бик борынгы, һәр токымның, һәм кавемнең үз культы, үз алласына табынган дәвергә барып тоташа һәм төрле илаһи затларга гыйбадәт кылган мәҗүсилек (Тәңречелек) дине йогынтысында формалаша. Тәңре – ул кояш, Күк-ата, Җир-Ана белән бәйле илаһи зат. Борынгы төркиләр, ислам динен кабул иткәнче, аңа гыйбадәт кылганнар. Тәңречелек эзләре хәзергә кадәр ышану-табынуларда да яхшы саклана. Тәңречелек эзләреннән күзгә ташланганы: ул Аллаһыны – Тәңрем, Ходай дип атау. Алай гына да түгел, Тәңречелек – яңа эраның башында гына барлыкка килгән Ибраһим пәйгамбәр диннәренең (иудалык, христианлык һәм Ислам) нигезе булып тора, дип әйтү дөреслеккә хилафлык булмас[7]. Бу уңайдан христианлык динендә бүгенге көндә дә шәхесләрне илаһилаштыру өстендә эш алып барыла. Ислам инкарь итүгә карамастан, бу күренеш ислам динендә дә очрый. Кайбер мөселман халыкларында аерым изгеләрнең, изге бабаларның, нәсел-ыру башында торган кайбер шәхесләрнең бүгенге көндә дә «ярдәм итүләре» хакында ышанулар хәзер дә популяр. Ислам дине йогынтысында күпмедер үзгәреш кичергән мондый ышанулар татарларда да мәгълүм.

Татарларда изге затлар, алар белән бәйле вакыйгаларны бәян иткән хикәятләр шактый. Татарлар яшәгән һәрбер регионда «изгеләр» белән бәйле, яки изге, дип саналган чишмәләр, таулар, зиратлар, каберләр очрый. Бу объектларның изгелеге бередә яшәгән, үлгән яки берәр вакыйга уңаеннан билгеле булган шәхес яки шәхесләр

исеме белән бәйләп атала. Татарларда бүгенге көндә дә әлеге культларны олылау, изгеләр каберенә зыярат кылу, алар кылган изге гамәлләрне искә алу, дога укыганда аларның исемен атап багышлау кебек йола-ритуаллар комплексы гамәлдә.

Ислам динендә, нигездә, Аллаһка якын булган, шәригать кануннарын төгәл үтәгән, шушы юлда шаһид киткән һәм үзе артыннан башкаларны да ияртә алган шәхесләрне изгеләштергәннәр. Ф. Х. Җәүһәрова изгеләр турындагы сюжетларны өйрәнеп, бу турыда «Изге исәпләнсен өчен аның изгелеген дәлилләүче фактлар комплексы булуы зарур. Бу төр легендаларны күз алдында тоткан тагын бер нәрсәне искә алырга кирәк. Ул легендаларның тулы, комплекслы туплау булганда гына аларны тикшереп, бәяләп була. Тулы комплекска нинди төр легендалар керә соң? Беренче чиратта әлеге урынның гади урын түгел, ә изге икәнлеген дәлилләүче, килеп чыгышына бәйле сөйләк-легенда исәпкә алынырга тиеш»[8], – дип яза. Мондый комплексның мөһим үзенчәлеге – әлеге изге урынның халык тарафыннан изге итеп кабул ителгән шәхес исеме белән бәйле булуы. Икенчесе – халыкның бу объектның могҗизалы көченә ышануы, бирегә сихәт, файда, шифа эзләп йөрүе белән бәйле. Фольклорда бу урынның могҗизалы булуы һәм әлеге сихәт-могҗизаның озак вакытлар дәвамында дәлилләнә килүе бәян ителә.

Бу сюжетка корылган риваять-легендаларны өйрәнү ата-бабалардан килгән дини-мәдәни мирасны өйрәнү һәм саклау ягыннан да әһәмиятле. Изгеләр турында, алар күрсәткән могҗизалы вакыйгалар турысындагы мотивларның татарларда популяр булуы суфичылык идеяләренең чагылышы белән дә бәйле булырга мөмкин. Суфичылык – ислам динен тотучының илаһият белән кушылуына юнәлдерелгән төрле системадагы дини-фәлсәфи карашлар һәм йолалар җыелмасы[9]. Аның нигезендә ислам белән бәйле мистика, аскетлык ята, шул ук вакытта аннан бераз хисси якка тайпылуга китерә. Суфи иҗтимагый тормыштан читләшергә, нәфес белән көрәшергә, бары Аллаһ исеме белән яшәргә тиеш. Суфичылык юлыннан киткән кешеләрне татарларда суфи, дәрвиш, «акыл иясе», «изге» дип атыйлар. Гади халык арасыннан чыккан суфилар иң элек үзенең яшәү рәвеше, үз-үзен тотышы, кылган гамәлләре белән башкаларга үрнәк, сүзләре белән эш-гамәлләре аерылгысыз кешеләр булганнар. Үз мисаллары белән халыкны төшенкелеккә бирелмәскә, фани дөнья кыйммәтләрен кайгыртып, бакыйлыкны онытмаска өндәгәннәр.

Суфичылык формалашуга яһүд, христиан диннәре, шулай ук мәҗүсилек зур йогынты ясый. Суфичылык, үз нәүбәтендә халык тормышында төрле яклап чагылыш таба. Бу матур әдәбиятта да күренә. Мәшһүр әдәбиятчы галимнәребез Г. Рәхим, Г. Газиз «Рәсми дин белән бергә безнең татарлар арасында, бик борынгы заманнардан ук алып, тасаувыф (суфичылык) әдәбияты да таралды. Шуның өчен үзебезнең дини әдәбиятыбызда суфилыкның бик көчле тәэсирен күрәбез»[10], – дип язалар. Гомумтөрки әдәбияты үрнәге «Котадгу белег» поэмасы (Йосыф Баласагуни, XI гасыр) суфичылык идеологиясеннән азат дип саналуга карамастан, анда ислам диненең, суфичылыкның йогынтысы ачык күренә. Ул аскет, сукбай, дәрвиш Одгурмыш образында ачык чагыла. Күп кенә әдәбият галимнәре аны шәех[11], – дип бирә.

Халык әдәбиятына, гомумән, халык иҗатына суфичылык йогынтысын ассызыклап М. Т. Степанянс болай ди: «Как бы ни была противоречива роль суфизма в истории мусульманства, не подлежит сомнению, что его влияние в области литературы было исключительно благотворным. Именно в поэзии в полной мере проявила себя “раскрепощающая” роль мистического восприятия, позволяющего через символы, метафоры выразить полет человеческой фантазии, неукротимый порыв к поиску

Идеала-Истины. Единственный реальный способ передачи истинного знания (хотя и он не до конца эффективен) – язык символов и знаков, стимулирующих воображение. Поэтому так много в суфийской литературе притч, иносказаний, метафор и т. п. Тому, кто не знаком с суфийской знаковой системой, практически не доступен глубинный смысл мистического текста»[12].

Татар фольклорында кешегә хас булмаган куәткә ия булган, вакыт һәм пространствода сәяхәт кылучы шәхесләр турындагы сюжетлар саклана. Алар җирдәге барлык нәрсәне дә күрә һәм аңлатып бирә алалар, кеше фикерен укый беләләр, авыруларны дәвалыйлар, һавадан яки судан йөриләр, бер үк вакытта берничә урында була алалар. Хәзер татар фольклорындагы сюжетлар белән танышып китик. Аларда изгеләр образы төрле яклап ачыла.

Татарларда Болгар чорыннан килгән риваятьләрдә ислам алып килгән сәхабә образлары турында сүз бара. Алар арасында иң популяры Мөхәммәд пәйгамбәрнең тугры хәлифе Әбүбәкер (Габдулла бине Нәһәде бине Сәгыйть бине Тим). Ул Хуҗвиринең «Кәйф-уль-Мәхҗүб» әсәрендә иң беренче суфи сәхабә буларак телгә алына[13]. Сәхабәләр – Мөхәммәт пәйгамбәрне күреп-белгән кешеләр. Татарлар исә нәсел-нәсәбе чылбырын Хәзрәти Әбүбәкер яки Сәлмән Фәрси белән бәйләп аңлата. Риваятьләр дүрт сәхабә Хәзрәти Әбүбәкер, Хәзрәти Гали, Хәзрәти Гомәр, Хәзрәти Госман исемнәре белән бәян ителә.

Илне саклаучылар турындагы риваятьләр Болгар һәм Казан ханлыгы чорына карый. Мәсәлән, Батыр кызлар турындагы сюжет башка төрки халыкларда да мәгълүм. Аның күпсанлы версияләре һәм вариантлары Татарстанның күп кенә районнарында да язып алынган. Бу риваятьләрдә кырык, унике, җиде кыз турында сүз бара. Шундый риваятьнең бер варианты «Татар халык иҗаты» күптомлыгының «Риваятьләр һәм легендалар» томында урын алган[14]. Аксубай районы Татар Сөнчәлесе авылында урнашкан Кызлар тавы, үзенең атама тарихы белән игътибарга лаеклы. Аны без 2019 елның 16 августында Аксубай районына фольклор-этнографик экспедиция вакытында Байдуганова Каусария Шигаповнадан язып алдык.

«Шул җирләрдә яшәгән бер хан үзенең бик матур кызын икенче бер хан егетенә кияүгә бирергә тели, әмма кызның сөйгән егете була. Әтисе, әлбәттә, ул егетне кияү итеп күрергә теләми. Кыз исә сөймәгән кешесенә барудан баш тарта. Хан кызы үзенең дус кызлары белән туган йорттан кача. Урманда озак кына качып йөргәннән соң, бер чокырлы җиргә килеп чыгалар һәм шул урында тирмә корып яши башлыйлар.

Көннәрдән бер көнне ата кызын алып кайтырга дип гаскәрен җибәрә. Кыз үзенең иптәш кызлары белән хан гаскәренә каршы тиңсез көрәшкә чыга. Тигезсез көрәштә алар барысы да һәлак була. Канлы бәрелеш булган җирдә кызларның үле гәүдәләреннән тау өелә. Менә шул тауны бүгенге көндә "Кызлар тавы", дип йөртәләр».

Бу урын халык арасында изгеләрдән санала. Корылык булганда монда килеп корбан чалалар, яңгыр сорап намаз укыйлар. Гомумән, бу урын күпмедер дәрәҗәдә Илаһи затларга табыну урыны да булып тора.

Татар халкында изге урыннар, диндар кеше исемнәре белән бәйле риваятьләр дә бик күп. Легендада тасвирланган каһарманнарның барлык сыйфатлары да күпертеп гиперболаштырып бирелә. Аларның иң популяры – Болгар ханы кызы турындагы «Янмый торган кыз» дигән риваяте[15]. Татарларда Ислам дини мифологиясе аша кергән Хозыр Ильяс образы гаять популяр. Хозыр Ильяс – терек су эчеп кыяматкәчә үлмичә яши торган пәйгамбәр. Ул гадәттә юлчы яки ярлы ак сакаллы карт кыяфәтендә

очрый, кешеләрдән ярдәм итүне үтенә. Ярдәм иткән кешенең киләчәге якты, ризыгы мул була. Шуңа да татар халкында «Мохтаҗларга ярдәм ит», дигән гыйбарә яши.

Риваятьләрдә күзгә күренми торган изгеләргә багышланганнары да очрый. Аларның асылында дөреслек эзләү, тәртип урнаштыру омтылышы ята. Гадәти шәхесләрне изге дип атау өчен, алар берничә сыйфатка ия булырга тиешләр. Алар бөтен дөньяви теләкләргә дә битараф, Аллаһның яраткан колы, нәфсе тыюлы, сөйләгәне хак, күңелләре пакь булырга тиеш. Һәм дә бу урында искәрмә ясау сорала. Алар нинди дер бер аерым милләткә бәйле түгел. Теләсә кайсы милләт кешесе, теләсә нинди җенестән була ала.

Ишаннарны, шәехләрне изгеләштерүгә багышланган сюжетлар халык яшәеше белән тыгыз бәйләнгән. Бүгенге көндә мондый вакыйгаларга реаль төсмер салып, конкрет җирлек белән бәйлиләр.

«Авылда бер кеше үлгән. Ни сәбәптәндер (сәбәпләре ачыкланмады, тик мәчет манараларын кискән заман булуына ишәрә ясалды, сәбәбе төрле булырга мөмкин, укый белүче кешеләрнең совет хөкүмәтеннән куркуыннан башлап, муллаларның шәхес культы корбаны булуына кадәр) авылда җеназа намазын укырга кеше булмый. Халык мәетне озатырга җыела, борчылышып тора, чөнки гасырлар дәвамында килгән йолаларны үтәү мөмкин түгел.

Шул чак Кызлар тавы ачыла һәм тарантаска утырып, яшел чапанлы, ак чалмалы ике ак сакаллы карт зияратка килә. Намаз укыла, мәетне тиешенчә җирлиләр. Халык шаккатып торган арада чапанлы картлар юкка чыгалар. Ләкин бу килгән кешеләрнең ничек юкка чыгуларын беркем дә күрми кала», – дип сөйләде информант Мифтахова Фәридә Миншакир кызы (Аксубай районында фольклор-этнографик экспедициясендә язып алынды).

Аксубай районы Яңа Ибрай авылы зиратында Хәмит бабай кабере бар. Аны авыл халкы әүлия буларак телгә ала. Ул күмелгән урынны Чәтрән кабере дип, изге урын буларак хөрмәтлиләр, барып намаз укыйлар, дога кылалар. Хәмит бабайның исеме белән бәйле вакыйганы бөтен авыл халкы горурланып сөйли. Бу картның тылсым-могҗиза элементларына ия булуы – аны изгеләр рәтенә кертергә мөмкинлек бирә. Бу яктан аның исеме дә мөһим: Хәмд (хәмед, хәмид, хәмит) – гарәпчә мактау, шөкер итү.

Җир йөзендә яшәүче бар халыкларнында оча торган кешеләр турында риваятьләре байтак. Очу сәләтенә ия булган иң борынгы геройлардан Хуандины (Кытай мифологиясе), Сампати һәм Этайюс (Һинд, «Рамос» эпосы) һәм башка бик күп образларны атап булыр иде. Бу уңайдан, татарлар да искәрмә түгел. Күп риваятьләрдә кешелек туган чордан башлап хыялланган очу күренеше үзәккә куеп тасвирлана. Кешене очарга этәрүче көч – Аллаһның кодрәте булуы ассызыклана.

Казан татарлары фольклорында изге Касыйм шәех образы бик популяр. Аны карәмәт иясе – изгелек кылырга сәләтле, могҗиза тудыра алучы, ярдәм-булышлык итә белүче санап, шәһәр халкы максатларына ирешер өчен нәзер әйтеп, бу шәех рухына сәдака бирәләр, корбан чалалар.

Бу уңайдан игътибарга лаек «Изге кеше» риваяте:

«Бервакыт Болгарга бер изге кеше килгән. Болгарларның падишасы хатыны белән икәве авыру булып сәламәтләнүдән өметләре тәмам беткән икән.

Шул изге адәм аларга әйткән:

– Әгәр дә сез минем динемне кабул итсәгез, мин сезне дәва кылырмын, – дигән.

Падиша хатыны белән, аның динен кабул итмәк булганнар. Бу кемсә дәва кылганнан соң, падиша хатыны белән икесе дә сәламәтләнгәннәр һәм исламны кабул

иткәннәр. Мәмләкәт әһлисе дә алар белән бергә мөселман булды. Бу вакыйганы Хәзәр падишасы ишеткән һәм зур гаскәр белән килеп, алар белән сугыш кылган.

Бу изге адәм ааларга әйткән:

– Сез курыкмагыз, аллага тәвәккәл итеп, үзләренә каршы торыгыз!

Һәм шул әйткәнчә, каршы торып, Хәзәр падишасын җиңделәр. Шуннан соң Хәзәр падишасы алар белән солых кылышты һәм әйтте:

– Мине сезнең гаскәрегездә олуг кешеләр күрдем. Алар күк атларга атланганнар һәм минем гаскәремне үтерделәр, – ди.

Ул изге кеше ааларга әйтте:

– Алар алланың безгә ярдәм өчен җибәргән гаскәрләредер, – ди.

Бу изге адәмнең исеме “Белар” иде, шуны үзгәртеп “Болгар” диделәр»[16].

Әсәрнең исеменнән күренгәнчә, халыкка Аллаһ сүзен җиткерүче изге кеше турында сүз бара. Аның төгәл исеме дә юк. Риваятьнең эчтәлегенә карасак, Болгар патшасының Ислам динен кабул итү вакыйгасы тасвирлана. Бу вакыйгага илткән сәбәпләр турында бәян ителә. Алда әйтелгәнчә, изгеләр табигать көчләренә таянып, Аллаһның ярдәме белән, авыру кешеләрне дәваларга, дошман гаскәрләрен җиңеп чыгарга сәләтле. Бу көчне ааларга Аллаһка тирән ышану бирә.

Татарлар арасында легенда-риваятьләр жанры бүгенге көндә дә киң таралган. Үрнәкләрен татарлар яшәгән бөтен төбәкләрдә табарга була. Алар тематик яктан гаять күптөрле, нигезендә ислам дине, бигрәк тә, суфичылык аркылы кергән мистик, тылсымлы вакыйгалар ята. Каһарман-персонажларга килгәндә, алар: туган җирен сакларга чыгучы гади кешеләр, хәтта кызлар, гадел патшалар, әүлияләр, әкияти тылсымлы көчкә ия булган затлар, фәлсәфи фикер ияләре, хәдисләрдән килгән пәйгамбәрләр.

Тормышта буталчыклар килеп чыкканда халык күбрәк илаһи көчләргә мөрәҗәгать итә, алардан ярдәм өмет итә, гомумән, тылсым-могҗиза көтә. Халык мәдәният, милли традицияләренә игътибар арту нәтиҗәсе буларак, соңгы вакытларда изге образларга, сакраль урыннарга ышаныч ныгый бара.

**ИСКӘРМӘЛӘР:**

1. *Арберри А. Дж.* Суфизм. Мистики ислама. Пер. с анг. – М.: Сфера, 2002. – С. 272; *Басилов В. Н.* Культ святых в исламе. – М.: Изд. «Мысль», 1970. – С. 144; *Бартольд В. В.* Сочинения. Т. 5 // Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов. – М.: Изд. «Наука», 1868 – С. 757; *Гольдциер И.* Лекции об исламе. – Санкт-Петербург: Брокгауз-Ефрон, 1912. – С. 302; *Исхаков Р. Р.* Миссионерство и мусульмане Волго-Камья (Последняя треть XVIII – начала XX в.). – Казань: Татар. книж. изд., 2011. – С. 221; *Насыров И. Р.* Основания исламского мистицизма (генезис и эволюция). – М.: Языки славянских культур, 2009. – С. 552; *Селезнев А. Г., Селезнева И. А.* Сибирский ислам: Региональный вариант религиозного синкретизма. – Новосибирск: Изд. Института археологии и этнографии СОРАН, 2004. – С. 72.

2. *Садекова А. Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество. – Казань: Изд-во «Фикер», 2001. – С. 208.

3. *Урманче Ф. И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 т.: 1 т. (А-Г). – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.; 2 т. (Д-С). – Казан: Мәгариф, 2009. – 343 б.; 3 т. (С-Я). – Казан: Мәгариф, 2011. – 199 б..

4. *Яхин Ф. З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: ТДГИ нәшрияты, 2000. – Б. 268; *Сибгатуллина Ә. Т.* Суфичылык серләре (төрки-татар шигъриятендә ди-

ни-суфичыл символлар, образлар, атамалар). – Казан: «Матбугат йорты»нәшр., 1998. – Б. 368.
5. *Закирова И. Г.* Болгар чоры халык иҗаты (Народное творчество булгарского периода). – Казан: Фикер, 2003. – 144 б.; Эпический фольклор периода Золотой Орды: мифологические и исторические основы. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2011. – С. 268; Әүвәл башлап ни бетте. – Казан: ТӘҺСИ, 2017. – Б. 152.
6. *Завгарова Ф. Х.* Татар изге урыннары һәм сакраль территорияләренә кагылышлы легендаларны туплау үзенчәлекләре // Татарская фольклористика. Исследование молодых. – Казань: Ихлас, 2013 – С. 4-13.; Комплексный подход в изучении татарских святынь и сакральных территорий // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. Материалы научно-практических конференций, проведенных РЦРТК. – Казань: Ихлас, 2013. – С. 12-14; *Уразманова Р. К.* Симбиоз этнического и конфессионального в современной праздничной культуре татар // Этнографическое обозрение. – 2010. – № 2. – С. 69-83.
7. *Сибгатуллина Ә. Т.* Суфичылык серләре… – Б. 17.
8. *Завгарова Ф. Х.* Изге урыннарга бәйле легенда // Урта Идел буе татарлары традицион мәдәнияте (материал туплау өчен сораулыклар җыентыгы). – Казан: Ихлас, 2013. – Б. 128.
9. Татар әдәбияты тарихы. 6 т.: 1 т. Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. – Б. 357.
10. *Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. 2 басма. – Казан, 1925. – Б. 149.
11. Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 1981. – Б. 29; *Фомкин М. С.* О суфийских мотивах в «Благодатном знании» Юсуфа Баласагуни // Советская тюркология. – 1990. – № 5. – С. 70; *Сибгатуллина Ә. Т.* Татар дини-суфи әдәбияты: югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Казан унив-ты нәшрияте, 2013. – Б. 21.
12. *Степанянц М. Т.* Поиск скрытого смысла // Предисловие к книге: В поисках скрытого смысла. Духовное учение Руми. – М.: Ладомир, 1995. – С. 10, 18.
13. *Сибгатуллина Ә. Т.* Суфичылык серләре… – Б. 48.
14. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар/Томны төз., кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С. М. Гыйләҗетдинов. – Казан: Татар. китап нәшр. 1987. – Б. 35.
15. Шунда ук. – Б. 34.
16. Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1963. – Б. 31-32.

**Әдәбият исемлеге**

*Бартольд В. В.* Сочинения. Т. 5 // Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов. – М.: Изд. «Наука», 1868. – С. 757.

*Басилов В. Н.* Культ святых в исламе. – М.: Изд. «Мысль», 1970 – С. 144.

*Завгарова Ф. Х.* Татар изге урыннары һәм сакраль территорияләренә кагылышлы легендаларны туплау үзенчәлекләре // Татарская фольклористика. Исследование молодых. – Казань: Ихлас, 2013 – С. 4-13.

*Исхаков Р. Р.* Миссионерство и мусульмане Волго-Камья (Последняя треть XVIII – начала XX в.). – Казань: Татар. книж. изд., 2011 – С. 221.

Татар халкының мифологик ышанулары (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы экспедиция язмалары буенча)/Кереш мәкалә авторы *Дәүләтшина Л. Х.*, төз. *Дәүләтшина Л. Х., Җәүһәрова Ф. Х.* – Казан: Ихлас, 2016. – Б. 199.

*Урманче Ф. И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 т.: 1 т. (А-Г). – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 303.

**References**

Bartold V. V. *Sochineniya. T. 5* [Essays]. IN: *Raboty po istorii i filologii tyurkskih i mongolskih narodov* [Works on the history and philosophy of Turkic and Mongolian peoples]. Moscow: Izd. "Nauka" publ., 1868, p. 757.

Basilov V. N. *Kult svyatyh v islame* [Saints cult in Islam]. Moscow: Izd. "Mysl'" publ., 1970, p. 144.

Zavgarova F. Kh. *Tatar izge urynnary hem sakral territoriyalyrene kagylyshly legendalarny tuplau uzencheleklere* [Research peculiarities of Tatars' sacred places]. IN: *Tatarskaya folkloristika. Issledovanie molodykh* [Tatar folkloristics. Young people's research]. Kazan: Ikhlas publ., 2013, p. 4-13.

Iskhakov R. R. *Missionerstvo i musulmane Volgo-Kamya (Poslednyaya tret XVIII – nachala XX v.)* [Missionary activities and Muslims of the Volga-Kama region (last third of the 18th – early 20th century]. Kazan: Tatar. knizh. izd. publ., 2011, p. 221.

*Tatar halkynyn mifologik yshanulary (XX gasyr ahyry – XXI gasyr bashy ekspeditsiya yazmalary buencha). Keresh mekale avtory, toz. L. Kh. Davletshina, F. Kh. Zheukherova* [Davletshina L. Kh., Zheykherova F. Kh. (eds.) Myths and legends of Tatar people (records of expeditions of the late 20th – early 21st century)]. Kazan: Ikhlas publ., 2016, p. 199.

Urmanche F. I. *Tatar mifologiyase. Entsiklopedik suzlek: 3 tomda: 1 t. (A-G)* [Tatar mythology. Encyclopedic dictionary: in 3 volumes. Vol. 1]. Kazan: Magarif publ., 2008, p. 303.

**Сведения об авторе**

***Самитова Савия Гималтыновна***, кандидат филологических наук, научный сотрудник Республиканского центра развития традиционной культуры, e-mail: savilas@yandex.ru.

**About the author**

***Saviya G. Samitova,*** Candidate of Philological Sciences, Researcher at the Republican Centre for Development of Traditional Culture, e-mail: savilas@yandex.ru.

**В редакцию статья поступила 13.11.2019, опубликована:**

*Сәмитова С. Г.* Татар фольклорында изгеләр образы // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2019. – № 4. – С. 166-173.

**Submitted on 13.11.2019, published:**

Samitova S. G. *Tatar folklorynda izgeler obrazy* [Images of Saints in Tatar folklore]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov*, 2019, no. 4, pp. 166-173.